**Исполнительный комитет Старочукалинского сельского поселения Дрожжановского муниципального района Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Башкарма комитеты**

422480 Республика Татарстан с.Старые Чукалы ул.Коминтерна д.21 тел/факс 34-1-12

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Иске Чокалы авылы

21 июль 2025ел №5

Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны кулланучылардан җыю һәм урнаштыру урыннары турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы «Җитештерү һәм куллану калдыклары белән тиешенчә җыю, туплау, файдалану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырткыч җайланмалар, электр лампалары өлешендә эш итү кагыйдәләрен раслау турында» карарына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Чүпрәле муниципаль районының Иске Чокалы авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны җыю һәм урнаштыру урыннарын әлеге карарга кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында терекөмешле лампаларны кулланучыларда терекөмешле лампаларны җыю һәм урнаштыру урыннарының урнашуы турында мәгълүмат урнаштырырга.

3. Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге башкарма комитетының түбәндәге карарларының үз көчен югалтуын танырга:

01.06.2018 ел, № 11 "Чүпрәле муниципаль районының Иске Чокалы авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны кулланучылардан җыю һәм урнаштыру урыннары турында";

22.06.2021 №12 "1.06.2018 № 11 карарына үзгәрешләр кертү турында".

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

Иске Чокалы авыл
Җирлеге Башлыгы: Р.Р.Низамутдинов

Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге башкарма комитетының 21 июль 2025 ел №5 карарына кушымта

**Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны кулланучылардан җыю һәм урнаштыру урыны**

| № | Помещение | Адрес |
|---|---|---|
| 1 | гараж | Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Чокалы авылы, Коминтерн ур., 12 (тел. 34-1-25) |